**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422612, РТ, Лаишевский район,
с.Курманаково, ул.Центральная, д.26-а
тел:89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422612, РТ, Лаеш район, Курманаково
авылы, Центральная ур, 26-а йорт
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

---

**2024 елның 11 ноябре** **50 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең Курманак торак пунктында гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегендәге Курманак торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең Курманак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2024 елда үзара салым салу акчаларын 3000 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Көек авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ___________________ Л.М.Сатдинова
(имза) (имза расшифровкасы)

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Көек
авыл җирлеге Советы рәисе: ___________________ Л.М.Сатдинова
(имза)(имза расшифровкасы)